**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

22 октябрь 2024 ел № 9

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 13 ноябрендә сәгать 11 сәгать 00 минутка Кооператив урамы, 78 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Кооператив урамы 1-61нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 13 ноябрендә 11 сәгать 30 минутка Кооператив урамы, 78 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Кооператив урамы 2-76нчы йортларда, Шоссе урамында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2025 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Чишмә поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- урамнарны яктырту җайланмасы.

РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чишмә поселогының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова